**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ШЕШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская
Крепость, 423104

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте
авылы, 423104

тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru

---

№17 12.03.2021ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге Советының
2019 елның 20 сентябрендәге 145 номерлы
карары белән расланган Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Шешминка
авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда
гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Чирмешән муниципаль районының «Шешминка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 сентябрендәге 145 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1) 1.7 пунктта өченче, дүртенче, бишенче абзацларны төшереп калдырырга;

2) 2.10 пунктта «Гражданнар җыены турындагы нигезләмә нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3.7 пунктта «(вариант буларак: форма Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән билгеләнә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 3.13 пунктында «(вариант буларак: форма Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән билгеләнә)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге Карар мәгълүмати стендта урнаштырылырга тиеш, Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Шешминка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе М.Д.Шәйхетдинов